ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.04.2025 Олы Кайбыч ав. № 196

Кайбыч муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 22 апрелендәге 190 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль учреждениесе җитәкчеләре һәм белгечләре хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль учреждениесе җитәкчеләренең һәм белгечләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 2025 елның 03 апрелендәге 03-12/2212 номерлы хаты нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Кайбыч муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль учреждениесе җитәкчеләренә һәм белгечләренә түләү шартлары турында (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш)» ( 07.02.2022 №57, 12.01.2024, № 8, 25.04.2024 №151, 08.11.2024 №403 үзгәрешләре белән) 2019 елның 22 апрелендәге 190 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль учреждениесе җитәкчеләре һәм белгечләре хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль учреждениесе җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Җитәкче   һәм белгеч вазыйфалары | Вазыйфаи   оклад, сум |
|---|---|
| | Муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 37 000 |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 34 600 |
| Бүлек башлыгы | 30 500 |
| Әйдәп баручы баручы бухгалтер | 27 800 |
| Бухгалтер | 26 400 |

Муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән бухгалтерия штат расписаниесенә җитәкче урынбасарының вазыйфасы кертү шарты булып, структурада һәрберсендә кимендә 5 берәмлек штат саны булган кимендә 3 бүлек булу тора.

Үзәкләштерелгән бухгалтерия бүлекләрендә штат саны кимендә 5 берәмлек булырга тиеш..».

2. Әлеге карар 2025 елның 1 маеннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча«Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Н.Макаров